**Кукмара муниципаль районы**
**Нырья авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**«10» март, 2022 ел** **№ 3**

**Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Кызыл Чәчәк авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставы нигезендә Нырья авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 21 мартына 11 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Кызыл Чәчәк авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Кызыл Чәчәк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы Кызыл Чәчәк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

2 пунктта «6500 сум» сүзләрен «2000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

«су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү өчен проект-смета документациясен эшләү, су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

- вак таш җәю һәм юлларны карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьлар сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Нырья авыл җирлеге башлыгы В.В. Васильев

ОГРН 1021607753111
ИНН 1623002336